Азнакай муниципаль районы мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе “Ләйсән” гомум үсеш төрендәге балалар бакчасының 1 категорияле тәрбиячесе Сунгатуллина Римма Владимир кызы.

Тема: “ Нәүрүз килде безгә.” ( Зурлар төркеме 4-7 яшь).

**Алып баручы:** Хөрмәтле ата-аналар, кадерле кунаклар, балалар! Без бүген бирегә язны - Нәурүзбикәне каршы алу бәйрәменә җыелдык. Бәйрәмдә халкыбызның дәртле җырларын, борынгы такмакларын ишетерсез, җырлы-биюле уеннарын күрерсез, үзегез дә дәртләнеп биерсез.

1)Әйдә, кояш, сип нурыңны,

Кызганма бер дә, Руслан

Зур бәйрәм, күңелле бәйрәм

Нәүрүз бүген бездә.

2)Тизрәк кил безгә, җылы яз,

Тизрәк-тизрәк кил! Әмир

Куяннар туңып беткәндер,

Иссен җылы җил.

3)Урманда бит җылы өй дә,

Җылы мич тә юк. Рәмис

Куяннарның әбиләре

Бәйләми оек.

4) Тизрәк кил безгә, җылы яз,

Тизрәк-тизрәк кил! Динә

Чыпчыкларга җырлар өйрәт,

Уйна, сайра, көл.

5)Урманда бит пешермиләр

Тугәрәк калач. Айзирәк

Песнәкләрнең туннары юк,

Тамаклары ач.

6)Чәчәкләр белән күмелсен

Без яшәгән ил. Айзилә

Тизрәк кил безгә, җылы яз,

Тизрәк-тизрәк кил!

**А.б.**Нәүрүз бәйрәме котлы булсын,

Эче тулы нур булсын!

Нәүрүз көен кем көйләсә

Ул дәртле һәм бай булсын!

**Нәүрүз көенә Нәүрүзбикә керә.**

**Нәүрүзбикә:**Гайбәт бетсен телегездә,

Орыш бетсен илегездә,

Ачу китсен йөзегездән,

Шулай икән-киләм сезгә!

Исәнмесез, балалар, хөрмәтле ата-аналар! Мин - Нәүрүзбикә! Язның иң гүзәл бәйрәме – Нәүрүз бәйрәменә килдем!

(Нәүрүзбикәне ипи-тоз белән каршылыйбыз. Нәүрүзбикә рәхмәт итеп ала һәм кешеләрне ашата.)

Хуш киләсең,гүзәл Нәүрүз!-

Язгы яңа елыбыз,

Яңа елда туры булсын, Рүзәл

Нурлы булсын юлыбыз!

Еракларга яңгырасын

Бүген дәртле җырыбыз.

**Җыр: “Килә яз”**

**Нәүрүзбикә:** Бәйрәмгә сез буш килмәгәнсездер дип уйлыйм.Минем белән бергә “кабыргалы-камчысы” уенын үткәреп алыйк.

**Уен: “Кабыргалы-камчысы”.**

1) Кабыргалы-камчысы,

Тама торган таягым,

Ал кирәк,күк кирәк

Бездән сезгә ни кирәк?

2) Кабыргалы-камчысы

Тама торган тамчысы.

Ал кирәк,күк кирәк

Динә матур кыз кирәк.

3)Җырласагыз бирәбез.

**Аб.** Нәүрүзбикә, үзең белән кемнәрне алып килдең?

**Нәүрүзбикә:**

Гөрләвек ага,

Кояш елмая.

Торналар үтте,

Тезелеп бая.

Гөрләвекләрдә

Уйный үрдәк,каз,

Илне яшәртеп,

Шаулап килә яз.

Мин үзем белән кошлар да алып килдем.

**Аб.**Әйдәгез кошлар,үзегез турында сөйләгез.

1.Кояш нурын сипте җир өстенә,

1.Истә йомшак җылы җилләре.

Кошлар кайта –сагындырган

Туып- ускән җирләре.

Көннәрен юлда үткәреп, Рәмилә

Куанышып очалар.

Канатларына күтәреп ,

Яз китерә ич алар.

Ямьле, бик ямьле

Туган илебез.

Килегез, кошкайлар

Безгә килегез!

2. Язын ерак – еराклардан

Очып килде каргалар,

Тал башына зур бер шәһәр Лиана

Тезеп куйдылар алар.

Без каршы алдык аларны

Үз итеп, сөеп,

Диңгез, чүлләрне исән- сау

Кичкәнсез диеп.

3. Ул сандугач- дус сандугач!

Көн дә бездә кунакта.

Минем өчен җырлар җырлый Диләрә

Бакчабызда – куакта.

Сайрагач ул матур итеп,

Бик күңелле миңа да.

“ Атказанган сандугач ” дип

Исем бирдем мин аңа.

4.Кошлар сайрый таңнарда

Кунып тирәк- талларга.

Ә тургайлар күккә менә

Сайрар урын сайларга. Рәйлә

Шаян сабан тургае

Күтәрелә югары

Ул, тирбәлә- тирбәлә,

Ярсып сайрап җибәрә

Җиргә моңнар түгелә.

5. Нинди якты уйлар уйлап,

Кыр казлары, кыйгак- кыйгак, Данис

Болын буйлап, кырлар буйлап

Кайта безгә язны зурлап.

Тезелешеп гаскәр кебек,

Ераклардан илләр гизеп,

Кычкыралар:”Кайттык урап

Исәнмесез,кыйгак-кыйгак”

6.Өй түрендә бакчада,

Талчыбык куначада

Сыерчык канат кага-                                Азалия

Яз килүгә шатлана.

Җилпенә ул,талпына,

Шатланып сайрап куя:

Ак каенның башында

Бик матур оя тора.

Кем ясаган ояны-

Сыерчык белә аны.

Чут-чут итеп сайравы-

Аның оя сайлавы.

**Нәүрүзбикә:**Күрәм балалар сез әтиләрегез-әниләрегез белән килгәнсез әйдәгез утырып арганнардыр,биетеп алыйк.

**Бию “Тыпыр-тыпыр”**

**Аб.**Әтиләр әниләр ял итеп алсыннар, ә без җыр җырлыйк.

Тып-тын һава, нурлар ява,

Көн аяз.

Бар дөньяга нулар сибеп

Килә яз.                                Сәрбиназ

Кил син, язым,тизрәк кил,

Бик сагынып көтәбез.

Җырлар җырлап,сөеп,зурлап,

Сине тәбрик итәбез!

Исәнме, яз, матур яз,

Безне сагынып килдеңме?                                Илдан

Агачларга, куакларга

Яшел чуклар элдеңме?

**Җыр: “Шатлык таратабыз”**

**Нәүрүзбикә:** Мин килгәч, карлар эрегәч кешеләр ниләр эшли башлыйлар? (җаваплар: орлыклар чәчеп язга әзерләнәләр.)

**Аб.** Хәзер безнең бәләкәчләр “Шалкан” әкиятен күрсәтәләр.

**Әкият : “Шалкан”**

**Нәүрүзбикә:** Мин үзем бит татар халык уенын “Чума үрдәк –чума каз” ны алып килдем.

**Уен: “Чума үрдәк –чума каз”**

**Аб.** Нәүрүзбикәне балалар сагынып көттеләр, аңа үзләренең җырларын җырлап күрсәтәләр.

**Фәрит, Рәмилә, Диләрә. “Уң ягымда дустым бар”**

**Нәүрүзбикә:** Рәхмәт балалар, җырыгыз бик матур.

**Аб.** Нәүрүзбикә үзе белән кояш җылысын алып килә, агачлар яфрак яра. Хәзер кызлар “Ак каен” җырына бию биеп күрсәтәләр.

**Бию: “Ак каен”**

**Нәүрүзбикә:** Биюегез бик матур, рәхмәт балалар.

**Аб.** Зурлар да сезгә күрсәтергә дип “Йомры икмәк” әкиятен хәзерләделәр.

**Әкият: “Йомры икмәк”**

**Аб.** Әтиләр-әниләр ардылар. Әйдәгез бергәләп “Кәрия-Зәкәрия” җырлы-биюне биеп алыйк.

**Җырлы-биюле уен: “Кәрия-Зәкәрия”**

Тамчы тама, тамчы тама,
Тамчы тама түгелме? Камил
Тамчы тамса, матур язлар
Килеп җитә түгелме?

**Аб:** Безнең кояш кебек көлеп тора торган малаебыз бар, ул да җыр җырлап узам ди. Әйдәгез аны тыңлап үтик.

**Җыр: “Гармун уйныйм”**

**Аб.** Балаларыгыз биибез дип кенә торалар

Бийченең итәге бии-бии кыскара,

Биючегә сүз әйтмәгез бии-бии остара.

**Мари биюе**

Бүген бездә бәйрәм була.

Инде менә ничә көн

Бик тырышып әзерләдек

Шушы бәйрәм кичәсен.

Шатлыклардан шатлык туа, Ильназ

Әверелә матур җырга.

Бары тик бер шатлык кирәк

Җир төренсен өчен нурга.

Авызларны ера шатлык-

Көлү булып йөзгә чыга.

Шатлык керсә бүлмәләргә,

Тәрәзәләр шыр ачыла.

**Җыр: "Әйлән-бәйлән"**

**Йомгаклап уен.**

**Соңгы җыр: "Кояшлы ил"**

**А.б.**Хөрмәтле әти-әниләр, укучылар! Сезне халкыбызның иң изге йолаларыннан берсе - Язгы яңа ел - Нәүрүз бәйрәме белән котлыйбыз. Саулык-сәламәтлек, бәхет, уңышлар телибез. Барлык өметләрегез дә чынга ашсын! Язгы Яңа ел котлы булсын! Нәүрүз мөбарәкбад!